**Татарстан Республикасы**
**Зәй муниципаль районының**
**Урсай авыл җирлеге Советы**

# КАРАРЫ

**03.10.2022 ел** **№59**

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Урсай авыл җирлеге территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә һәм физик һәм юридик затларның хосусый милкендәге җирләргә кермәгән яшел үсентеләрне кисү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында»**

Россия Федерациясе Урман кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Урсай авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Урсай авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Урсай авыл җирлеге территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә һәм физик һәм юридик затларның хосусый милкендәге җирләргә кермәгән яшел үсентеләрне кисү тәртибе турында нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.
2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
3. Карарны "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU), Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Урсай авыл җирлеге Советы рәисе** **Н.А.Гатина**

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Урсай авыл җирлеге Советының 03.10.2022ел№59
номерлы карарына кушымта.

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Урсай авыл җирлеге территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә һәм физик һәм юридик затларның шәхси милкендәге җирләргә кермәгән
яшел үсентеләрне кисү тәртибе турында
НИГЕЗЛӘМӘ

Әлеге нигезләмә Россия Федерациясе Конституциясе, Россия Федерациясе Гражданнар кодексының 15 статьясы, Россия Федерациясе Урман кодексы, «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль законның 61, 68, 77 статьялары, Урсай авыл җирлеге Уставы нигезендә халыкның экологик иминлеген тәэмин итү максатында эшләнде һәм Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Урсай авыл җирлеге территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә һәм физик һәм юридик затларның шәхси милкендәге җирләргә кермәгән яшел үсентеләрне кисү тәртибен билгели.

1. Төп төшенчәләр

Әлеге нигезләмәдә түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

Яшел үсентеләр - агач, куак һәм үлән үсә торган табигый һәм ясалма үсемлек (шул исәптән парклар, скверлар, бакчалар, газоннар, чәчәклекләр, шулай ук аерым торучы агачлар һәм куаклар).

Табигый территорияләр - бердәм географик (климат) шартларда формалашкан җир рельефының, туфракның, үсемлекләрнең билгеле бер тиналарын үз эченә алган хуҗалык эшчәнлеге белән кагылмаган яисә аз кагылган территорияләр.

Яшелләндерелгән территорияләр - табигый барлыкка килгән үсемлекләр участоклары, ясалма яшелләндерү объектлары (авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән тыш), төрле функциональ билгеләнештәге җирләрнең 50 проценттан да ким булмаган өлешен үсемлекләр капламы алып торган аз төзелгән участоклары.

Урман территорияләре - төрле функциональ билгеләнештәге табигый территорияләр участоклары, алар табигый барлыкка килгән урман үсемлекләре белән капланган.

Агач - 5 см диаметрлы төгәл гәүдәле, 1,3 м биеклектә, үсентеләрдән тыш, үсемлек.

Куак - күпьеллык күпботаклы (агачтан аермалы буларак) үсемлек, ул туфрак өслеге янында ботаклана.

Үлән капламы - газон, табигый үлән үсемлеге.

Үсентеләр - нинди дә булса урында үсә торган үсемлекләр, куаклар.

Яшел массив - бердәм үсентеләр үсә торган урын барлыкка китерүче 50 данәдән дә ким булмаган (15 яшьтән өлкәнрәк) агач үсә торган территория участогы.

Яшел үсентеләргә зыян китерү - аларның үсешен туктату, шул исәптән ботакларга, тамыр системасына механик зыян китерү, тамырның бөтенлеген, тере туфрак катламын бозу, яшел үсентеләрне яисә тамыр зонасындагы туфракны зарарлы матдәләр белән пычрату, ут төртү яки башка төрле йогынты ясау.

Яшел үсентеләрне юк итү (югалту) - яшел үсентеләрне кисү яки башкача зыян китерү, аларның үсешен туктату.

Компенсацияле яшелләндерү - юк ителгән яки зарарланган белән яшел утыртмаларны 2 коэффициенты белән яңадан торгызу.

## 2. Яшел үсентеләрне саклауның төп принциплары

Авыл җирлеге территориясендә үсә торган яшел утыртмалар саклагыч, рекреацион, эстетик функцияләрне башкара һәм алар сакланырга тиеш.

2.1. Авыл җирлеге территориясендә (авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән тыш) урнашкан барлык яшел утыртмалар (агачлар, куаклар) сакланырга тиеш.

2.2. Авыл җирлеге территориясендә яшел үсентеләрнең сакланышын һәм үсешен тәэмин итү буенча бурыч оешмаларга үзләре билдергән эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыру өчен бирелгән участокларда - әлеге оешмалар җитәкчеләренә йөкләнә;

2.3. Яшел утыртмалар урнашкан җир кишәрлекләрен кулланучылар һәм арендалаучылар яшел утыртмаларның сакланышын тәэмин итәргә, яшел үсентеләрне тиешенчә карарга тиеш.

2.4. Авыл җирлеге территориясендә хуҗалык, шәһәр төзелеше һәм башка төр эшчәнлек Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнары һәм әлеге нигезләмә белән билгеләнгән яшел үсентеләрне саклау таләпләрен үтәп башкарыла.

2.5. Төзелеш, хуҗалык һәм башка эшчәнлекне оештыруга проект алды һәм проект документларында яшел утыртмаларның торышы турында тулы һәм дөрес белешмәләр булырга һәм проектлана торган объектның яшел утыртмаларга йогынтысы тулысынча бәяләнергә тиеш.

2.6. Яшел утыртмаларның үсешен тәэмин итү белән ярашмый торган максатларда яшел территорияләрне һәм яшел массивларны куллану рөхсәт ителми.

## 3. Яшел үсентеләрне (агачлар, куакларны) кисү тәртибе

3.1. Авыл җирлеге территориясендә яшел үсентеләрне үз белдегең белән (рөхсәтсез) кисү тыела.

3.2. Авыл җирлеге территориясендә агач һәм куакларны кисү рөхсәтнамә нигезендә башкарыла. Кисүгә рөхсәт кәгазе авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе күрсәтмәсе рәвешендә рәсмиләштерелә.

Рөхсәт бирү тәртибе авыл җирлеге башкарма комитеты карары белән расланган агач һәм куакларны кисүгә, ябалдашларын формалаштыруга яисә утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты белән билгеләнә.

3.3. Рөхсәт кәгазе мөрәҗәгать итүченең салымнар, җыемнар, иминият взнослары, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча Россия Федерациясенең Салымнар һәм җыемнар турында законнары нигезендә түләнергә тиешле бурычлары булмаганда бирелә.

3.4. Авыл җирлеге башкарма комитеты хат-гариза кергәннән соң, гариза бирүчегә әлеге төр эшләрне башкару өчен рөхсәте булган махсус оешмага түбәндәгеләрне алу өчен мөрәҗәгать итәргә киңәш итә:

3.4.1. яшел утыртмаларның исәп-хисап исемлеген;

3.4.2. киселергә тиешле агач утыртмаларының санын, төрен, категориясен билгеләү максатларында төзелә торган яшел үсентеләрне натураль тикшерү актын;

3.4.3. киселгән агач өчен түләү (түләүләр) исәбен. Киселгән агач өчен түләү Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2007 елның 22 маендагы 310 номерлы карары белән расланган ставкалар нигезендә аерым исәпләнә.

Югарыда күрсәтелгән эшләрне башкару гариза бирүче хисабына башкарыла.

Рөхсәтнең гамәлдә булу срогы - 90 көн.

3.5. Эшләрне башкаруга рөхсәт алган вакытта аның мәнфәгатьләрендә яшел үсентеләр юкка чыгарылачак гариза бирүче әлеге нигезләмә буенча яшел үсентеләр кискән өчен түләү кертергә һәм компенсацияле яшелләндерү тәртибен раслый торган документларны тапшырырга тиеш.

3.6. Агач һәм куак кискән өчен түләү гариза бирүче тарафыннан авыл җирлеге бюджетына күчерелә.

3.7. Яшел үсентеләрне кисү эшләре билгеләнгән нормаларга һәм кагыйдәләргә туры китереп, гариза бирүче акчасы хисабына башкарыла. Агач кисү бары тик аттестацияләнгән белгечләргә генә рөхсәт ителә.

3.8. Агачларны егу, түмәрләү, киселгәннәрне, чүп-чарны төяп чыгару эшләр башланганнан соң өч көн эчендә гариза бирүче хисабына башкарыла.

3.9. Киселү урынына якын территориядә газонга, яшел үсентеләргә зыян килгән очракта, территория хуҗасы һәм контрольлек итүче органнар белән аларның компетенциясе чикләрендә килештерелгән срокларда, ләкин зыян килгән мизгелдән ярты елдан да соңга калмыйча, эш башкаручы тарафыннан мәҗбүри рәвештә алар яңадан торгызыла.

3.10. Түләмичә агач һәм куакларны кисү түбәндәге очракларда авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан рөхсәт ителә:

3.10.1. яшел үсентеләрне матурлау, тәрбияләү ниятеннән кисү, санитар кисүләр, реконструкция;

3.10.2. авария һәм башка гадәттән тыш хәлләрне бетерү, шул исәптән җир асты коммуникацияләрен һәм капиталь инженерлык корылмаларын ремонтлау вакытында кисү;

3.10.3. Госсанэпидемнадзор бәяләмәсе булса, торак һәм җәмәгать биналарында ут режимын бозучы агач һәм куакларны кисү;

3.10.4. авария куркынычы тудырган (ауган, корыган) агач һәм куакларны кисү;

3.11. Югарыда күрсәтелгән очракларда яшел үсентеләр кисүне гамәлгә ашыручы мөрәҗәгать итүчегә авыл җирлеге башкарма комитеты белән килештерелгән урыннарда компенсацияле яшелләндерүне үткәрү зарур.

3.12. Авария хәлендәге, корыган һәм иминлеккә куркыныч тудырган яшел үсентеләр акт буенча комиссия тикшерүе нигезендә киселә.

3.13. Яшел үсентеләрне санкциясез кисү яки юк итү дип түбәндәгеләр таныла:

3.13.1. агачлар һәм куакларны рөхсәтсез кисү яисә рөхсәт буенча, әмма тиешле булмаган участокта, тиеш булмаган санда, агач төрләре рөхсәттә күрсәтелгәнчә булмаганда;

3.13.2. ут төртү яки ут белән саксыз эш итү нәтиҗәсендә агач һәм куакларны юк итү яки аларга зыян китерү;

3.13.3.  кәүсәне бөҗралау яки төпләү;

3.13.4. агачлар һәм куакларның үсешен туктатырлык дәрәҗәдә зыян салу;

3.13.5. агач һәм куакларга юынтык сулар, химик матдәләр, калдыклар белән зыян китерү һ. б. шундыйлар;

3.13.6. корыган агачларны рөхсәтсез кисү;

3.13.7. үсеп утырган агачларга һәм куакларга башка зыян салу.

4. Компенсацияле яшелләндерү

4.1. Компенсацияле яшелләндерү рөхсәт ителгән агач кисү, законсыз рәвештә яшел үсентеләрне зарарлау яки юк итү очракларында гамәлгә ашырыла. Компенсацияле яшелләндерү агачлар, куаклар һәм газоннар утырту өчен туры килә торган, әмма яшел үсентеләрне зарарлау яки юк иту факты билгеләнгәннән соң бер елдан да соңга калмыйча башкарыла.

4.2. Компенсацияле яшелләндерү кем мәнфәгатьләрендә яисә кемнең хокукка каршы гамәлләре нәтиҗәсендә яшел үсентеләр зыян күргән яки юкка чыгарылган, шул гражданнарның яисә юридик затларның акчалары исәбеннән башкарыла.

4.3. Әлеге нигезләмәдә билгеләнгәнчә, яшел үсентеләргә китерелгән зыян натураль рәвештә кайтарылырга тиеш –компенсацияләү рәвешендә яшелләндерү: юкка чыгарылган яшел үсентеләрне 2 коэффициенты белән яңадан торгызу.

5. Шәһәр төзелеше эшчәнлеген башкарганда яшел утыртмаларны саклау

5.1. Авыл җирлегендә шәһәр төзелеше эшчәнлеген гамәлгә ашыру яшел үсентеләрне саклау таләпләрен үтәп алып барыла.

5.2. Яшел территорияләр, шул исәптән яшел массивлар, шулай ук яшелләндерелгән территорияләрне киңәйтү өчен билгеләнгән җир кишәрлекләрендә төзелеш алып барылырга һәм аларның максатчан билгеләнешенә бәйле булмаган юнәлештә кулланылырга тиеш түгел.

5.3. Яшел үсентеләр биләгән җир кишәрлекләрендә төзелеш эшләре планлаштырылганда, алдан проектлау документларында киселергә тиешле яшел үсентеләр бәяләнергә тиеш. Бу очракларда килгән зыянны каплау әлеге нигезләмәнең 2 һәм 3 бүлекләрендә билгеләнгән тәртиптә киселгән агач өчен түләүне алдан кертү һәм компенсация рәвешендә яшелләндерү юлы белән гамәлгә ашырыла.

6. Эшкуарлык эшчәнлеге башкарга нда яшел утыртмаларны саклау

6.1. Яшелләндерелгән территорияләрдә һәм яшел массивларда сәүдә итү һәм башка эшкуарлык эшчәнлеге алып бару, авыл җирлеге башкарма комитеты рөхсәтеннән башка эшкуарлыкны гамәлгә ашыру өчен палаткалар һәм башка корылмалар урнаштыру тыела.

6.2. Яшелләндерелгән территорияләрдә һәм яшел массивларда эшмәкәрлекне гамәлгә ашырганда шартлау куркынычы булган, янып китү куркынычы тудырган һәм агулы матдәләр куллану, территорияне пычрату һәм чүпләү, яшел утыртмаларга зыян китерү яисә аларны юкка чыгару тыела.

7. Административ җаваплылык

7.1. Әлеге Нигезләмәне бозуда гаепле затлар Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә җаваплылыкка